# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен табышка салым буенча салым ставкасын билгеләү турында" 2006 елның 10 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 2 (I өлеш); 2009, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**"1 статья**

1. Татарстан Республикасы Алабуга районы территориясендә төзелгән сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона оешмалары-резидентлары өчен (алга таба – оешмалар-резидентлар) Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган табышка карата түбәндәге күләмнәрдә билгеләргә:

0 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап биш календарь ел эчендә;

5 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап алтынчы календарь елдан алып унынчы календарь ел тәмамланганчы;

13,5 процент – салым салынырга тиешле табыш беренче тапкыр алынган салым чорыннан башлап 10 календарь ел үткәннән соң.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән салым ставкалары махсус икътисадый зона территориясендә гамәлгә ашырыла торган эшчәнлектән алынган (эшчәнлеккә тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) һәм эшчәнлекне махсус икътисадый зона территориясеннән читтә гамәлгә ашырганда алынган (эшчәнлеккә тотылган) керемнәрнең (чыгымнарның) оешмалар-резидентлар тарафыннан аерым исәп алып бару шарты белән кулланыла.";

2) 2 статьяның беренче абзацында "һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта" сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2013 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән соң бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 11 июне
№ 34-ТРЗ